**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменения в Указ Президента Республики Татарстан «О мерах по реализации отдельных положений Закона Республики Татарстан «О государственных должностях Республики Татарстан» в части обеспечения права на доплату к пенсии»**

В соответствии со статьей 15 Закона Республики Татарстан от 4 марта 2006 года № 16-ЗРТ «О государственных должностях Республики Татарстан» **постановляю:**

1. Внести изменение в пункт 1 Указа Президента Республики Татарстан от 6 августа 2011 года № УП-480 «О мерах по реализации отдельных положений Закона Республики Татарстан «О государственных должностях Республики Татарстан» в части обеспечения права на доплату к пенсии» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 5 апреля 2013 года № УП-276 и от 23 ноября 2013 года № УП-1143), заменив слова «равен 1,5-кратному размеру» словами «равен 2-кратному размеру».

2. Установить, что лицам, замещавшим государственные должности Республики Татарстан, которым доплата к пенсии назначена до вступления в силу настоящего Указа, размер доплаты к пенсии подлежит перерасчету с 1 января 2017 года, но не ранее дня возникновения права на нее, с применением положений пункта 1 Указа Президента Республики Татарстан от 6 августа 2011 года № УП-480 «О мерах по реализации отдельных положений Закона Республики Татарстан «О государственных должностях Республики Татарстан» в части обеспечения права на доплату к пенсии» в редакции настоящего Указа.

3. Кабинету Министров Республики Татарстан обеспечить в установленном порядке финансирование расходов, связанных с реализацией настоящего Указа.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казань, Кремль
16 марта 2017 года
№ УП-228

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләрен пенсиягә өстәмә түләү хокукын тәэмин итү өлешендә гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәреш кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләрен пенсиягә өстәмә түләү хокукын тәэмин итү өлешендә гамәлгә ашыру чаралары турында» 2011 елның 6 августындагы ПУ-480 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 5 апрелендәге ПУ-276 номерлы, 2013 елның 23 ноябрендәге ПУ-1143 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 пунктына, «1,5 тапкыр күләменә тигез» сүзләрен «2 тапкыр күләменә тигез» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ үз көченә кергәнче пенсиягә өстәмә түләү билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затларга пенсиягә өстәмә түләү күләме 2017 елның 1 гыйнварыннан яңадан исәпләнергә тиеш, әмма әлеге Указ редакциясендә Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләрен пенсиягә өстәмә түләү хокукын тәэмин итү өлешендә гамәлгә ашыру чаралары турында» 2011 елның 6 августындагы ПУ-480 номерлы Указының 1 пункты нигезләмәләрен кулланып, бу исәпләү өстәмәгә хокук барлыкка килгән көннән дә иртәрәк башкарылырга тиеш түгел.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 16 март
№ ПУ-228